



# Дәреснең темасы:

**Тезмә кушма җөмләләрне кабатлау.**

**(зачёт дәрес)**

**Максат.**Тезмә кушма җөмлә турындагы белемнәрне гомумиләштереп кабатлау; кушма җөмләләрне танып белү; синтаксик анализ ясау һәм сөйләмдә куллану күнекмә-ләрен камилләштерү;үз эшеңә, иптәшләреңнең хезмәтенә бәя биреп, нәтиҗә ясап, фикереңне дәлилли белү күнекмәләрен үстерү; әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

*Тырышлык - зурлык,*
*ә ялкаулык – хурлык.*

(мәкаль.)

- Нинди җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала?

- Тезмә кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?

-Нинди җөмлә теркәгечле тезмә кушма җөмлә дип атала?

-Нинди җөмлә теркәгечсез тезмә кушма җөмлә дип атала?

-Теркәгечле тезмә кушма җөмләдә гади җөмләләр нинди теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә?

-Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре арасына нинди тыныш билгеләре куела?

- Кайсы очракта өтер куелмый?

-Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә гади җөмләләр үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнәләр?

-Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдәге гади җөмләләр арасына нинди тыныш билгеләре куела?

-Кайсы очракта өтер, нокталы өтер, кайсы очракта сызык куела?

-Рус телендә тезмә кушма җөмләләр бармы? Алар ничек атала?

- Һөнәрле үлмәс, **һөнәрсез көн күрмәс.**

Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

- Эшләгән тук булган, **ә эшләмәгән юк булган.**

Теркәгечле тезмә кушма җөмлә.

- Вакытның кыйммәте **алтыннан артык.**

Гади җөмлә.

- Яман гадәт әрәм итәр, **яхшы гадәт адәм итәр.**

Теркәгечсез тезмә кушма җәмлә.

1.Кайсы билгеләмә ***тезмә кушма җөмләләргә*** туры килә?

а) үзара иярту юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора;

ә) гади җөмләләрне үзара кушымчалар ярдәмендә бәйләнә;

б) гади җөмләләрне үзара янәшә тору юлы белән бәйләнә;

в) үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора.

**2.Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре..**

а) үзара интонация ярдәмендә бәйләнә;

ә) тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә;

б) теркәгеч сүзләр ярдәмендә бәйләнә;

в) иярткүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә;

**3.Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре арасында нинди тыныш билгеләре куела?**

а) нокталы өтер;

ә) өтер;

б) сызык;

в) ике нокта.

**4.Бай дигән даны бар, тик чыкмаган җаны бар**

дигән җөмләнең төрен билгеләргә.

а) гади җөмлә;

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;

б) иярченле кушма җөмлә;

в) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

**5.Теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнә?**

а) кушымчалар;

ә) мөнәсәбәтле сүзләр;

б) санау һәм каршы кую интонациясе;

в) янәшә тору юлы белән.

**6.Ашарга чакырдылар кермәдем** җөмләсендә нинди тыныш билгесе куела?

а) өтер;

ә) сызык;

б) нокталы өтер;

в) ике нокта.

1.Кайсы билгеләмә ***тезмә кушма җөмләләргә*** туры килә?

а) үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора;

ә) гади җөмләләрне үзара кушымчалар ярдәмендә бәйләнә;

б) гади җөмләләрне үзара янәшә тору юлы белән бәйләнә;

в) үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора.

**2.Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре..**

а) үзара интонация ярдәмендә бәйләнә;

ә) тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә;

б) теркәгеч сүзләр ярдәмендә бәйләнә;

в) ияртүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә;

**3.Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре арасында нинди тыныш билгеләре куела?**

а) нокталы өтер;

ә) өтер;

б) сызык;

в) ике нокта.

**4.Бай дигән даны бар, тик чыкмаган җаны бар**

дигән җөмләнең төрен билгеләргә.

а) гади җөмлә;

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;

б) иярченле кушма җөмлә;

в) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

**5.Теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнә?**

а) кушымчалар;

ә) мөнәсәбәтле сүзләр;

б) санау һәм каршы кую интонациясе;

в) янәшә тору юлы белән.

**6.Ашарга чакырдылар кермәдем** җөмләсендә нинди тыныш билгесе куела?

а) өтер;

ә) сызык;

б) нокталы өтер;

в) ике нокта.

# Җөмләләргә синтаксик анализ ясарга.

а)Чәчәкләр бии болында,
Җил курай уйнап тора.

ә)Кичләре салкын, тәрәзә пыяласын көмеш абагалар бизәкли.

б)Юлчылар ташларга тотыналар, ләкин көчле шарлавык басымы астында зур-зур ташлар да урыннарыннан кузгала.

Хезмәтнең тире ачы - җимеше татлы.

Тышта ябалак-ябалак кар ява һәм буран котыра иде.

# Мөстәкыйль эш.

I вариант. Нуриәсма аның чагуын көтте, ләкин корт чакмады.

II вариант. Аның күзләре елтырый, үзе бик сәер итеп елмая иде.

# Тезмә кушма җөмлә

## Теркәгечле тезмә кушма җөмлә

**Бәйләүче чаралар**

*тезүче теркәгечләр:*

-җыючы теркәгечләр

-каршы куючы теркәгечләр

-бүлүче теркәгечләр

## Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

**Бәйләүче чаралар**

*тезү интонациясе:*

-санау интонациясе

-каршы кую интонациясе

| **Мисаллар** | **Кушма җөмләдәге гади җөмләләрне үзара бәйли торган <u>тезүче теркәгечләр</u>** |
|---|---|
| Җәй җитте һәм кызу эш башланды. | Җыючы теркәгечләр: һәм, да,дә, да-да, ни-ни, янә-янә |
| Ул үзе урманга караган төсле, әмма күңел күзе бик еракта кебек күренә. | Каршы куючы теркәгечләр: ләкин, ә, әмма, тик, бары, бәлки. |
| Я салкын җил исә, я яңгыр ява башлый. | Бүлүче теркәгечләр:я-я, яки, яисә, әллә-әллә, әле-әле. |

| **Мисаллар** | **Бәйләүче чаралар** |
|---|---|
| Көне-төне кар ява, җил ыжгыра, туктаусыз буран уйный. | Санау интонациясе. |
| Бер барды, ике барды – тегесе өйдә булмады. | Каршы кую интонациясе. |

*Тырышлык - зурлык,*
*ә ялкаулык – хурлык.*

(мәкаль.)